СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.06.2019 г. Заинск № 406

**Зәй муниципаль район Советының 2011 елның 14 декабрендәге 139 номерлы «Шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен бушлай бирелә торган җир кишәрлекләре күләмен билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасының 2018 елның 22 декабрендәге 114-ТРЗ номерлы «Гражданнарга бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында «Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль район Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль район Советының 2011 елның 14 декабрендәге 139 номерлы «Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга индивидуаль торак төзелеше, дача төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен бушлай бирелә торган җир кишәрлекләре күләмнәрен билгеләү турында» гы карарына (Зәй муниципаль район Советының 2012 елның 4 июнендәге 185 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1.1. Карар атамасында «дача төзелеше» сүзләрен төшереп калдырырга;
   1.2. 3 пунктта «дача төзелеше» сүзләрен төшереп калдырырга.
2. Зәй муниципаль район Советы оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATASTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Советының Экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г.Кәримов**